Балачакны ташлап чыгып киттек,
Ерагая һаман арабыз.
Балачаклар кире кайтмас инде,
Ләкин без бит кайта алабыз.
Балачак ул безнең ишек алды,
Капка төбе, урам чатлары,
Бабайларның әле исән чагы,
Әнкәйләрнең дә яшь чагы,
Балачак ул безнең бишегебез,
Нигезебез, туган ягыбыз.
Әллә шуңа, олыгайган саен
Балачакка тарта җаныбыз.
Балачакның яшел урамнары
Безне сагынып каршы алачак.
Әгәр кайтмый калсак, беркайчан да
Гафу итмәс безне балачак.

Р.Миңнуллин

Балачаклар кире кайтмас инде,
Ләкин без бит кайта алабыз !
Р.Миңнуллин




Максат :

1. Талантлы шагыйрь , балалар шагыйре Роберт Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру.

2.Аның шигырьләренә күзәтү ясау, үзенчәлекләрен билгеләү.

3. Роберт абый иҗатына мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү.






**Кошлардагы туган җирне сөю**
**Һәм сагыну миңа, аһ, таныш.**
**Мин Сөн кошы! Ике канатымның**
**Берсе – Илеш, берсе – Актаныш!**


**И Актаныш! Күпме җырларымны**
**Талларыңа кунып сайрадым.**
**Туган җирне сайлап алмыйлар да,**
**Сине менә үзем сайладым.**


Р.Миңнуллин



Роберт Миңнуллин
СӨЕНСЕННӘР ӘЛЕ САБЫЙЛАР


Сладкая крапива


РОБЕРТ МИННУЛЛИН
Әнкәйнең ак гөлләре


НАШ ТИГРЁНОК


Роберт Миңнуллин


Мәйдан
ЧАЛЛЫ
Роберт Миңнуллин


Роберт Миңнуллин
Шагыйрь генә булып калмадым...


* Балалар көлүе.


Балаларның көлешкәнен
Ишетсен Җир, тыңласын Җир!
Балаларның көлүеннән
Берчакта да тынмасын Җир!
Р.Миңнуллин.



Роберт Миңнуллин
ХӘРЕФЛӘР БӘЙРӘМЕ
Шигъри әлифба
XƏREFLƏR BƏYRƏME
Şiğri əlifba


Роберт Миннуллин


РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН
Әнкәй безне Сөннән алып кайткан...


Роберт Миннуллин
Мальчик, каких ещё мир не видал


Роберт Миңнуллин
Дөньядагы иң зур алма




Роберт Миннуллин
Ох уж эти взрослые!

* Юк инде...
Әтиемнең бар белгәне:
-Кимә! Тимә! Тотынма!
Әниемнең бар белгәне:
-Килмә! Көлмә! Тотынма!
Әбиемнең бар белгәне:
-Япма! Ятма! Котырма!
Доктор:
Улыгыз гел уйнасын,
Берегез дә тыймасын!
Кисен, тисен, тотынсын,
Япсын, ятсын, котырсын!
Р.Миңнуллин



# Дәрәҗәле исемнәре

- Муса Җәлил исемендәге премия иясе
- Абдулла Алиш исемендәге премия иясе
- “Дөньядагы иң зур алма” исемле китабы
  өчен Г.Х.Андерсен исемендәге Почетлы
  диплом белән бүләкләнде.




- “Күчтәнәч” исемле балалар китабы өчен Габдулла Тукай
- исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

*Сабый чаклар гөрләвектәй
Еракларга акты микән?
Туган өйдә күргән төшләр
Әле булса татлы микән?
Мин бит синдә туган идем,
Исеңдәме, туган өем?
Сабый чактан йөри минем
Сиңа дигән шушы көем
**Туган өйнең тәрәзәләре**
**Әле булса татлы микән?**
**Җаннарыма җылы җитми**
**Әнкәй мичен якты микән?**
**Ничек басыйм сусавымны?**
**Әнкәй чәен куя микән?**
**Кайтасымны күңелләре**
**Тоя микән? Тоя микән?**

Р. Миңнуллин